РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

САБИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН

СОВЕТ БОЛЬШЕНЫРТИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

422063, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Большие Нырты, ул.М.Джалиля, д.13 а
тел. (884362) 45-2-32

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

ОЛЫ НЫРТЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422063, Татарстан Республикасы, Саба районы, Олы Нырты
авылы, М.Джэлил урамы, 13 а йорт
тел. (884362) 45-2-32

---

РЕШЕНИЕ — КАРАР

19.10.2022 — №14

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Олы Нырты авыл җирлеге Советының 2018 нче елның
27 нче апрелендә кабул ителгән 5 нче номерлы
«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Олы Нырты авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының
депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм
муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары
турында " гы карарына үзгәрешләр кертү турында»

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2022 №881 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге Советы

Карар итте:

1. 2022 елның 1 октябреннән Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге Советының 27.04.2018 ел, № 5 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларына, сайланулы вазыйфаи затлары һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә» гә таянып, Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге башлыгының, депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен 1,04 тапкырга арттырырга.

2. 2022 елның 1 октябреннән Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә»не 27.04.2018 № 5 карары белән билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең вазыйфа окладлары күләмен арттырырга.

3. Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладлары күләмнәрен исәпләү өчен әлеге карарның 2 пункты нигезендә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең

вазыйфа оклады күләмен 1,04 тапкыр индексацияләргә һәм аны 11 958 сум күләмендә билгеләргә.

4. Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге Советының 27.04.2018 № 5 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә” карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1.2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгече вазифа окладын 11 958 сум күләмендә расларга.»;

4.2.1нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә, әлеге карар өчен 1нче кушымта нигезендә җиткерергә.

5. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына, әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 2022 елның 1 октябреннән гамәлдә булу башлангач, яңа штат расписаниеләрен расларга.

6. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү, тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

7. Әлеге карар 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә гамәлгә ашырыла.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru һәмТатарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/nirti адреслары буенча бастырып чыгарырга.

Олы Нырты авыл җирлеге башлыгы Р.З.Сәфәргалиев

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Олы Нырты авыл җирлеге Советының
2022 елның 19 октябре, № 14 карарына

Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының акчалата бүләкләре күләме

| Вазыйфалар исемнәре акчалата бүләк күләме (сумнарда) | акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Авыл җирлеге башлыгы | 16390 |
| Депутатлар | 11958 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 11958 |